ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22.11.2018 ел | №21

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «19» ноябрь 2018 елдагы № 920 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Урта Кирмән авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе Б.Ф.Хасанов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябре 18 нче карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Урта Кирмән авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 28.02.2019 вакытка кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш,

1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә яраксыз,

б) хезмәт буенча командировка,

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин,

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына муниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгару һәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге лицевой счетына

күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Урта Кирмән авыл
җирлеге
башкарма комитетының 2018
елның 18 нче карарына 2 нче
кушымта

Урта Кирмән авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзарасалым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________
Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_____________________________________________________________________
Адрес:
_____________________________________________________________
Нигезләмә: Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 920 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында
Сезгә 2019 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум чараларын тормышка ашыру өчен 400 сум күләмендәге түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы Татарстан Республика НБ бүлеге, БИК 049205001
Сч. № ________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180 ОКАТО 92638480
Түләүнең билгеләнеше

Җитәкче ________________ Хасанов Б.Ф.____________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Урта Кирмән авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне
_______________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.

Түләүченең Ф.И.Ә.и.

______________________________________________

Адрес:

______________________________________________

Кабул ителде «__» ______________ 201 ел.

______________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*